СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 351 от 29.04.2020

на № _ от ________

# К А Р А Р

Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге контроль һәм эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 11 сентябрендәге 256 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге контроль һәм эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 11 сентябрендәге 256 номерлы карарына Саба муниципаль районы Прокуратурасының 2020 елның 3 мартындагы 02-02-70-2020 номерлы протестын карап тикшергәннән соң һәм “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында “Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге контроль һәм эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 11 сентябрендәге 256 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге контроль  буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында”;

**1.2.** карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге контроль  буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен расларга”.

**2.** Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 11 сентябрендәге 256 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге контроль  буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1.** 6 пунктны төшереп калдырырга;

**3.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан  Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы  http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**4.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов